Урта Комар авыл җирлеге Советы

КАРАР

18 сентябрь, 2024 ел

№ 28

Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 05 апрелендәге 1 номерлы Урта Комар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Урта Комар авыл җирлеге Уставы нигезендә Урта Комар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 30 сентябренә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 05 апрелендәге 1 номерлы Урта Комар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Урта Комар авылы, Май урамы, 1Г йорты адресында урнашкан мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 30 сентябренә 11 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 05 апрелендәге 1 номерлы Урта Комар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Урта Комар авылы, Май урамы, 1Г йорты адресында урнашкан мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Урта Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләреннән; 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме» мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 05 апрелендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Урта Комар авылындагы чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскыч урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Урта Комар авылы чишмәләрен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Урта Комар авылын су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Урта Комар авылына янгын гидрантларын сатып алу, көйләү, ремонтлау һәм урнаштыру һәм янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча башка эш төрләре)

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Урта Комар авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

- торак пункт территориясен төзекләндерү (спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Урта Комар авылы спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (урам-юл челтәрен карап тоту, Урта Комар авылында юлларга вак таш салып төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, ягулык-майлау материаллары һәм МТЗ тракторына комплектлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Урта Комар авылы юлларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка жиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, Урта Комар авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм Урта Комар авылының яр буе зоналарын, сулыкларын чистарту буенча башка эш төрләре)

- торак пункт чикләрендә жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен жир өсте кичүләрен ремонтлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру Урта Комар авылының җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен жир өстендәге кичүләрне ремонтлау буенча башка эш төрләре)

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын жыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне

гамәлгә ашыру каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар төзү һәм рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча башка эшләрне гамәлгә ашыру)

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне һәм Урта Комар авылының тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эшләрне гамәлгә ашыру)

2024 елның 05 апрелендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эшләр белән тулыландыру өлешендә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, агачларны кисү һәм карап тоту, проект-смета документлары)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы С.В. Федоров

ОГРН 1021607752891
ИНН 1623001660